

# ТАТАРЧА СӨЙЛӘШӘБЕЗ

5–6 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү
буенча методик ярдәмлек

Уйный-уйный
Үсәбез

Казан

ХӘТЕР

2012

© HETER P.H.

УДК 512.145
ББК 81.2Тат
Т23

Комплектның авторлары:
**Зарипова Зифа Мирхәт кызы, Кидрәчева Раушания Гайнулла кызы, Шәрипова Лена Әхмәди кызы, Исаева Резедә Сәлман кызы, Алексеева Рәфисә Муллаяр кызы, Камалова Алсу Имам кызы, Камалова Аида Дамир кызы, Ситдыйкова Венера Рөстәм кызы, Нургалиева Минзада Салих кызы**

Рецензентлары:
**С. М. Гаффарова** —
*Казан педагогика көллиятенең директор урынбасары, РФнең Мактаулы урта һөнәри белем бирү хезмәткәре*
**Н.М. Шириева —**
*Яр Чаллы шәһәре 25 нче балалар бакчасының татар теленә өйрәтүче тәрбияче*

Тышлык рәссамы ***Юлия Щетинкина***

ISBN 978-5-94113-392-5

© Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы, 2012
© Татарстан Республикасы
«ХӘТЕР» нәшрияты, 2012

© ХӘТЕР

## «УЙНЫЙ-УЙНЫЙ ҮСӘБЕЗ» ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ТЕМАТИК ПЛАН (ЗУРЛАР ТӨРКЕМЕ)

| АКТИВ СҮЗЛӘР | СӨЙЛӘМ ҮРНӘГЕ | АУДИОЯЗМА<br>ЭШ ДӘФТӘРЕ<br>МУЛЬТФИЛЬМ |
|---|---|---|
| | **КАБАТЛАУ – 3 СӘГАТЬ (1–3)** | |
| | «Минем өем» проекты буенча | Аудиоязма № 1<br><br>Дәфтәрдә эш № 1<br><br>Мультфильм:<br>«Шалкан» |
| | **ЯШЕЛЧӘЛӘР – 21 СӘГАТЬ (4–24)** | |
| кишер<br><br><br><br>баллы<br><br>ничә<br><br>суган<br>бәрәңге<br><br><br>кыяр<br>кәбестә<br>нинди<br><br>алты<br>җиде<br>сигез<br>тугыз<br>ун | – Бу нәрсә?<br>– Кишер.<br>– Мә кишер.<br><br>– Нинди кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)?<br>– Зур (кечкенә) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр).<br>– Мә зур (кечкенә) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр).<br>– Рәхмәт.<br><br>– Зур кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр).<br>– Кечкенә кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр).<br>– Чиста кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр).<br>– Пычрак кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр).<br><br>– Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) нинди?<br>– Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) тәмле, зур (кечкенә), матур, чиста (пычрак).<br><br>Кишер баллы.<br>Алма баллы.<br>– Мә, кишер (алма) аша. Баллы?<br>– Әйе, баллы. Рәхмәт. | Аудиоязма № 2–24<br><br>Дәфтәрдә эш № 2–6<br><br>Мультфильмнар:<br>1. «Баллы кишер»<br>2. «Уйный-уйный эшлибез»<br>3. «Юл маҗаралары»<br>4. «Кем эшләми, шул ашамый» |

| АКТИВ СҮЗЛӘР | СӨЙЛӘМ ҮРНӘГЕ | АУДИОЯЗМА<br>ЭШ ДӘФТӘРЕ<br>МУЛЬТФИЛЬМ |
|---|---|---|
| | – Ничә кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)? Сана.<br>– Ике (1–10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр).<br><br>– Оля, кил монда. Мә, ике (1–10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр).<br>– Ике (1–10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр).<br><br>– Оля, кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) бир.<br>– Мә, кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер).<br>– Рәхмәт.<br><br>– Коля, (1–10) кәбестә (суган, бәрәңге, кишер, кыяр) бир.<br>– Мә, (1–10) кәбестә (суган, бәрәңге, кишер, кыяр).<br>– Сау бул, Коля.<br><br>– Ничә кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер)?<br>– Бер (1–10) кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер).<br>– Кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) пычрак. | |
| кызыл<br>сары<br>яшел | – Бу туп.<br>– Туп (алма) нинди?<br>– Туп (алма) сары (кызыл, яшел).<br><br>– Нинди туп (алма) юк?<br>– Кызыл (сары, яшел) туп (алма) юк. | |
| нәрсә кирәк? | – Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) кирәк?<br>– Кирәк. | |

© НЕТЕР Р.Н.

| АКТИВ СҮЗЛӘР | СӨЙЛӘМ ҮРНӘГЕ | АУДИОЯЗМА<br>ЭШ ДӘФТӘРЕ<br>МУЛЬТФИЛЬМ |
|---|---|---|
| | – Коля, нәрсә кирәк?<br>– Кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) кирәк.<br>– Нинди кыяр?<br>– Яшел (тәмле, чиста) кыяр.<br><br>– Кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) пычрак.<br>– Мә, кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) ю. | |
| юа | – Оля кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) юа. | |
| **АШАМЛЫКЛАР – 6 СӘГАТЬ (25–30)** | | |
| аш<br>ботка | тәмле аш (ботка, сөт, ипи, чәй).<br><br>– Нәрсә кирәк?<br>– Аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) кирәк.<br>– Нинди аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге)?<br>– Тәмле аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге).<br>– Мә, аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) аша (эч).<br>– Рәхмәт. Аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) тәмле. | Аудиоязма №25–29<br><br>Дәфтәрдә эш №7, 8<br><br>Мультфильм:<br>«Аш бүлмәсе» |
| **САВЫТ-САБА – 6 СӘГАТЬ (31–36)** | | |
| кашык<br>тәлинкә<br><br>чынаяк<br><br>зәңгәр | – Кашык (тәлинкә, чынаяк) бир.<br>– Нинди кашык (тәлинкә, чынаяк)?<br>– Зур (кечкенә, сары, яшел, кызыл, зәңгәр).<br>– Ничә кашык (тәлинкә, чынаяк)?<br>– (1–10) кашык (тәлинкә, чынаяк).<br>– Мә, (1–10) кашык (тәлинкә, чынаяк).<br>– Мә, кызыл (сары, яшел, зәңгәр) кашык (тәлинкә, чынаяк). | Аудиоязма №30–37<br>Дәфтәрдә эш №9, 10<br>Мультфильмнар:<br>1. «Өч аю»<br>2. «Чисталыкта – матурлык» |

© НЕПЕР Р.Н.

| АКТИВ СҮЗЛӘР | СӨЙЛӘМ ҮРНӘГЕ | АУДИОЯЗМА<br>ЭШ ДӘФТӘРЕ<br>МУЛЬТФИЛЬМ |
|---|---|---|
| | **КИЕМНӘР – 6 СӘГАТЬ (37–42)** | |
| күлмәк<br>чалбар<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>ки<br>сал<br><br><br><br><br><br><br>йокла | Яшел (кызыл, сары, зәңгәр) күлмәк (чалбар).<br><br>Чиста күлмәк (чалбар).<br>Матур күлмәк (чалбар).<br><br>Күлмәк (чалбар) юк.<br><br>– Оля, күлмәк (чалбар) бир.<br>– Нинди күлмәк (чалбар)?<br>– Сары (кызыл, яшел, зәңгәр) күлмәк (чалбар).<br>– Ничә күлмәк (чалбар)?<br>– Бер (1–10) күлмәк (чалбар).<br><br>– Курчак, чалбар (күлмәк) ки (сал).<br><br>– Оля, чалбар (күлмәк) бир.<br>– Мә, чалбар (күлмәк).<br>– Рәхмәт. Курчак, мә, чалбар (күлмәк) ки (сал).<br><br>– Курчак, йокла. | Аудиоязма №38–43<br><br>Дәфтәрдә эш №11, 12<br><br>Мультфильм:<br>1. «Киемнәр кибетендә»<br>2. «Шаян уенчыклар» |
| | **ШӘХСИ ГИГИЕНА – 3 СӘГАТЬ (43–45)** | |
| бит<br>кул<br>хәерле көн | – Хәерле көн.<br>– Мә су, бит (кул) ю.<br><br>– Бит (кул) чиста.<br><br>– Бит (кул) чиста.<br>– Әйе, бит (кул) чиста. | Аудиоязма № 43, 44–48<br><br>Эш дәфтәре №13, 14<br><br>Мультфильм:<br>1. «Ни өчен киемнәр югалган?» |
| | **ӨЙ ҖИҺАЗЛАРЫ – 3 СӘГАТЬ (46–48)** | |
| өстәл<br>урындык<br>карават | – Зур (кечкенә) урындык (өстәл, карават).<br><br>– Зур аю, мә зур карават (өстәл, урындык).<br>– Кечкенә аю, мә кечкенә карават (өстәл, урындык). | Аудиоязма № 49<br><br>Эш дәфтәре №15<br><br>Мультфильм:<br>«Маша һәм өч аю» |

<table>
<tr><th>АКТИВ СҮЗЛӘР</th><th>СӨЙЛӘМ ҮРНӘГЕ</th><th>АУДИОЯЗМА<br>ЭШ ДӘФТӘРЕ<br>МУЛЬТФИЛЬМ</th></tr>
<tr><td></td><td>– Нәрсә кирәк?<br>– Карават (өстәл, урындык) кирәк.<br>– Нинди карават?<br>– Зур (кечкенә, сары, яшел, зәңгәр) карават.<br>– Мә, зур карават.<br>– Рәхмәт.</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="3">БӘЙРӘМ «ТУГАН КӨН» – 9 СӘГАТЬ (49–57)</td></tr>
<tr><td>яратам<br><br><br><br><br><br><br><br><br>бар</td><td>– Мин алма (ипи, сөт, чәй, ботка, аш, кыяр, кәбестә, бәрәңге, кишер) яратам.<br><br>– Мин Коля(ны) (Оля(ны) яратам.<br><br>– Мин курчак(ны) (аю(ны), песи(не), эт(не), куян(ны) яратам.<br><br>– Нәрсә бар?<br>– Туп (курчак) бар.<br>– Нәрсә юк?<br>– Туп (курчак) юк.<br>Бар, юк сүзләрен кулланып, «Гаилә», «Яшелчә», «Уенчыклар» темаларын кабатлау.<br>Диалогларны кабатлау.<br>«Кибетле» уеннары.</td><td>Аудиоязма № 50–60<br><br>Эш дәфтәре №16–19<br><br>Мультфильмнар:<br>1. «Туган көн»<br>2. «Кем нәрсә ярата?»</td></tr>
<tr><td colspan="3">БӘЙРӘМ «САБАНТУЙ» – 3 СӘГАТЬ (58–60)</td></tr>
<tr><td></td><td>Ел дәвамында өйрәнелгән сүзләр, сөйләм үрнәге кулланыла.<br>«Гаилә», «Яшелчә», «Уенчыклар» темаларын кабатлау.<br>«Кибетле» уеннары.</td><td>Аудиоязма № 61–63<br><br>Мультфильм:<br>«Сабантуй бәйрәме»</td></tr>
</table>

© HEFER.Н

## УЙНЫЙ-УЙНЫЙ ҮСӘБЕЗ

**Максат:** Информацион-коммуникатив технологияләр, уен-ситуацияләр, күргәзмәлелек кулланып тел өйрәнү, аралашу теләге тудыру.

**Бурычлар:** 1. Сүз байлыгы булдыру.

2. Гади диалогта катнаша белү, сүзләрне отып алу аша хәтер, зиһен үстерү.

3. Татар теленә кызыксыну уяту.

| Тема | Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| 1. «Минем өем» | | **1. Дидактик уен «Өйдә кем яши?»**<br>**Өй макеты, әни, әти, малай, кыз рәсемнәре күрсәтелә.**<br>**Тәрбияче:** Какой красивый дом. Давайте вспомним: кто живет в этом доме?<br>– Бу кем?<br>**Балалар:** Әти, әни, малай, кыз.<br>**Тәрбияче:** Давайте их позовем.<br>**Балалар:** Әни, кил монда. Исәнме, әни. Хәлләр ничек?<br>**Әни:** Әйбәт.<br>**Һәр гаилә әгъзасын шул үрнәктә бер-бер артлы чакыралар.**<br>**2. Уен ситуациясе «Әби белән бабай бездә кунакта».**<br>**Балалар әби белән бабай ролендә.**<br>**Ишек шакыган тавыш.**<br>**Тәрбияче:** Кем анда?<br>**Бабай:** Мин – бабай.<br>**Әби:** Мин – әби.<br>**Балалар белән тәрбияче:** Бабай, кил монда. Әби, кил монда.<br>**3. Аудиоязманы тыңлау, кушылып җырлау.**<br>*Аудио (1 нче кисәк)*<br>**Җырлы-биюле уен «Минем өем».**<br>**Балаларга бабай, әби, әти, әни, кыз, малай, эт, песи битлекләре таратыла.**<br>Бу өй матур,<br>Бу өй зур.<br>Монда яши бабай. | Өй макеты.<br>Күрсәтмә рәсемнәр: әти, әни, кыз, малай, эт Акбай, песи Мияу, әби, бабай.<br>Битлекләр: әти, әни, кыз, малай, эт Акбай, песи Мияу, әби, бабай.<br>Аудиоязма 1. |

<table>
<tr><th>Тема</th><th>Актив сүзләр (сөйләм үрнәге)</th><th>Эш төрләре</th><th>Җиһазлау</th></tr>
<tr><td></td><td></td><td>Бабай алга чыга: Мин – бабай.<br>Монда яши әби.<br>Әби алга чыга: Мин – әби.<br>Монда яши әти.<br>Әти алга чыга: Мин – әти.<br>Монда яши әни.<br>Әни алга чыга: Мин – әни.<br>Монда яши малай.<br>Малай алга чыга: Мин – малай.<br>Монда яши кыз.<br>Кыз алга чыга: Мин – кыз.<br>Әйе шул, әйе шул,<br>Бу өй матур.<br>Бу өй зур.</td><td></td></tr>
<tr><td>2. «Кем юк?»</td><td></td><td><u>1. Аудиоязмага кушылып җырлау.</u><br><u>Аудио (1 нче кисәк)</u><br><u>Җырлы-биюле уен «Минем өем».</u><br>Балаларга бабай, әби, әти, әни, кыз, малай, эт, песи битлекләре таратыла.<br>Бу өй матур,<br>Бу өй зур.<br>Монда яши бабай.<br>Бабай алга чыга: Мин – бабай.<br>Монда яши әби.<br>Әби алга чыга: Мин – әби.<br>Монда яши әти.<br>Әти алга чыга: Мин – әти.<br>Монда яши әни.<br>Әни алга чыга: Мин – әни.<br>Монда яши малай.<br>Малай алга чыга: Мин – малай.<br>Монда яши кыз.<br>Кыз алга чыга: Мин – кыз.<br>Әйе шул, әйе шул,<br>Бу өй матур,<br>Бу өй зур.</td><td>Эш дәфтәре.<br>Аудиоязма 1.</td></tr>
</table>

© НЕТЕР Р.Н.

| Тема | **Актив сүзләр** *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| | | **2. Дидактик уен «Кем юк?»**<br>**Әти, әни, әби, бабай, кыз, малай, песи, эт рәсемнәре кулланып оештырыла.**<br>**3. Дәфтәрдә эш. 1 нче бирем «Угости».**<br>***Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була.*** | |
| 3. «Шалкан» әкияте | | **Мультфильм «Шалкан» әкияте.** | |
| 4. «Кишер үстерәбез» | кишер<br>*Сөйләм үрнәге: нинди?* | **1. Сәхнәләштерелгән уен «Кишер үстерәбез».**<br>***Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була.***<br>**Балаларга әби, бабай, әти, әни, малай, кыз, эт, песи битлекләре таратыла. Түтәлдә «кишер» үсә.**<br>**Тәрбияче:** Что растет на грядке? Давайте вытянем вместе и посмотрим.<br>**Тәрбияче үзе тартып карый, саный:** 1, 2, 3, 4, 5. Юк. Бабай, кил монда.<br>**Бабай тартып карый:** 1, 2, 3, 4, 5. Юк. Әби, кил монда.<br>**Бергә тарталар:** 1, 2, 3, 4, 5.<br>**Әби:** Юк. Әти, кил монда.<br>**Бергә тарталар:** 1, 2, 3, 4, 5.<br>**Әти:** Юк. Әни, кил монда.<br>**Бергә тарталар:** 1, 2, 3, 4, 5.<br>**Әни:** Юк. Малай, кил монда.<br>**Бергә тарталар:** 1, 2, 3, 4, 5.<br>**Малай:** Юк. Кыз, кил монда.<br>**Бергә тарталар:** 1, 2, 3, 4, 5.<br>**Кыз:** Юк. Эт, кил монда.<br>**Бергә тарталар:** 1, 2, 3, 4, 5.<br>**Эт:** Юк. Песи, кил монда.<br>**Бергә тарталар:** 1, 2, 3, 4, 5.<br>**Тартып чыгаралар:** О-о-о! Зур! | Битлекләр: әби, бабай, әти, әни, кыз, малай, эт, песи.<br>Төрле зурлыктагы кишер муляжлары.<br>Таратма рәсемнәр: чиста кишер, пычрак кишер, зур кишер, кечкенә кишер.<br>Аудиоязма 2. |

| Тема | Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| | | **Тәрбияче:** Бу нәрсә? Кишер.<br>**Тәрбияче белән балалар:** Кишер.<br>**<u>2. Сүзле уен «Мә, кишер».</u>**<br>**Балалар кишер муляжын бер-берсенә бирәләр, әйтәләр:** Мә, кишер.<br>***Кишер*** **сүзе яңа сүз бирү алымнары кулланып өйрәтелә.**<br>**<u>3. Дидактик уен «Сорап ал».</u>**<br>**Тәрбиячедә муляжлар: зур кишер, кечкенә кишер.**<br>**Бала:** Кишер бир.<br>**Тәрбияче:** Нинди кишер?<br>**Бала:** Зур (кечкенә) кишер.<br>**Тәрбияче:** Мә, зур (кечкенә) кишер.<br>**Бала:** Рәхмәт.<br>**<u>4. Дидактик уен «Нинди кишер?»</u>**<br>***Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була.***<br>**Балаларда таратма рәсемнәр: чиста кишер, пычрак кишер, зур кишер, кечкенә кишер.**<br>**Аудиодан ишеткән сүзтезмәгә туры килгән рәсемнәрне бала күрсәтә, әйтә.**<br>*<u>Аудио (2 нче кисәк)</u>*<br>Зур кишер. Кечкенә кишер. Чиста кишер. Пычрак кишер.<br>**Уен шулай дәвам итә.** | |
| 5. «Куян күчтәнәче» | баллы | **<u>1. Уен «Куян күчтәнәче».</u>**<br>**Уенчык куян керә. Кәрзинендә һәр балага җитәрлек кишер, алма муляжлары.**<br>**Тәрбияче:** К нам в гости пришел зайчик. Давайте посмотрим, что он принес.<br>– Бу нәрсә?<br>**Балалар:** Кишер. | Таратма рәсемнәр: чиста кишер (алма), пычрак кишер (алма), зур кишер (алма). |

© НЕТЕР Р.Н.

| Тема | **Актив сүзләр** *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| | | **Тәрбияче:** Кишер нинди?<br>**Балалар:** Кишер тәмле, зур (кечкенә), матур, чиста.<br>**Куян кишерне «ашап» карый:** Баллы.<br>***Баллы* сүзе яңа сүз бирү алымнарын кулланып өйрәтелә.**<br>**Шул ук эшчәнлек *алма* сүзе белән кабатлана.**<br>**<u>2. Уен ситуациясе «Балаларны сыйла».</u>**<br>**Куян һәрбер балага кишер (алма) бирә:** Мә, кишер (алма) аша. Баллы?<br>**Бала:** Әйе, баллы. Рәхмәт.<br>**<u>3. Аудиоязманы тыңлау, кушылып җырлау.</u>**<br>*<u>Аудио (3 нче кисәк)</u>*<br>Кишер, кишер,<br>Тәмле кишер.<br>Зур кишер,<br>Баллы кишер. | Кечкенә кишер (алма).<br>Уенчык куян.<br>Кәрзин.<br>Һәр балага җитәрлек кишер, алма муляжлары.<br>Аудиоязма 3. |
| 6. «Баллы кишер» | | **<u>Мультфильм «Баллы кишер».</u>** | |
| 7. «Серле кәрзин» | ничә<br>*Сөйләм үрнәге: сана.* | **<u>1. Уен ситуациясе «Акбай күчтәнәче»</u>**<br>**Уенчык Акбай ишек шакый. Кәрзинендә биш кишер.**<br>*<u>Аудио (4 нче кисәк).</u>*<br>**Ишек шакыган тавыш.**<br>**Тәрбияче:** Кто-то стучится в дверь. Давайте спросим:<br>– Кто там? – Кем анда?<br>**Балалар белән тәрбияче:** Кем анда?<br>**Акбай:** Һау-һау. Мин – Акбай.<br>**Балалар белән тәрбияче:** Акбай, кил монда.<br>**Ишек ачылган тавыш.** | Һәр балага җитәрлек кишер муляжлары.<br>Уенчык эт.<br>Кәрзин.<br>Уенчыклар: куян, эт, песи, курчак, аю.<br>Аудиоязма 4–5. |

| Тема | Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| | | **Акбай:** Исәнмесез, балалар.<br>**Балалар:** Исәнме, Акбай. Хәлләр ничек?<br>**Акбай:** Әйбәт.<br>**<u>2. Дидактик уен «Серле кәрзин».</u>**<br>**Балалар кәрзиндә нәрсә барын уйлап әйтәләр, бергәләп саныйлар.**<br>**Тәрбияче:** Ребята, у Акбая корзина. Давайте узнаем, что там?<br>**Акбай:** Бу нәрсә? (Кәрзиндә кишерләр.)<br>**Балалар:** Алма?<br>**Акбай:** Юк.<br>**Балалар:** Кишер?<br>**Акбай:** Әйе. Сколько? – Ничә кишер? Сана.<br>**Акбай кишерләрне күрсәтә, бергәләп саныйлар.**<br>**<u>3. Үстерешле уен «Ничә, әйт».</u>**<br>**Акбай Мияуга кишер бирә, ничә икәнен әйтә.**<br><u>*Аудио (5 нче кисәк).*</u><br>**Акбай:** Мияу, кил монда. Кишер ал.<br>**Мияу:** Ничә кишер?<br>**Акбай:** Ике кишер.<br>**Мияу:** Рәхмәт.<br>**Уен балалар белән шул үрнәктә дәвам итә.**<br>**<u>4. Уен ситуациясе «Сыйла».</u>**<br>**Балалар алдында уенчыклар. Акбай белән бергәләп уенчыкларны чакыралар, сыйлыйлар.**<br>**Бала:** Куян (аю, песи, эт, курчак), кил монда. Утыр (утырталар). Мә, куян, кишер. Аша.<br>**Куян:** Рәхмәт.<br>**Бала:** Кишер баллымы?<br>**Куян:** Әйе, баллы. | |

© НЕТЕR Р.Н.

| Тема | **Актив сүзләр** *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| 8. «Сыйлыйбыз» | | <u>**1. Дидактик уен «Серле кәрзин».**</u><br>**Балалар Мияуның кәрзинендә нәрсә барын беләләр, бергәләп санныйлар.**<br>**Тәрбияче:** Ребята, у Мияу корзина. Давайте узнаем, что там?<br>**Мияу:** Бу нәрсә? (кәрзиндә алмалар).<br>**Балалар:** Кишер?<br>**Мияу:** Юк.<br>**Балалар:** Алма?<br>**Мияу:** Әйе. Ничә алма? Сана.<br>**Мияу алмаларны күрсәтә, бергәләп саныйлар.**<br><u>**2. Уен ситуациясе «Сыйла».**</u><br>**Балалар алдында уенчыклар. Акбай белән бергәләп уенчыкларны чакыралар, сыйлыйлар.**<br>**Бала:** Куян (аю, песи, эт, курчак), кил монда. Утыр (утырталар). Мә, куян, кишер. Аша.<br>**Куян:** Рәхмәт.<br>**Бала:** Кишер баллы?<br>**Куян:** Әйе, баллы.<br><u>**3. Дәфтәрдә эш. 2 нче бирем «Угости зайцев».**</u><br>***Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була.*** | Һәр балага җитәрлек кишер, алма муляжлары.<br>Уенчык песи Мияу.<br>Кәрзин.<br>Эш дәфтәре. |
| 9. «Бар матур бакча» | | <u>**Аудиоязманы тыңлау, кушылып җырлау.**</u><br><u>*Аудио (6 нчы кисәк)*</u><br><u>**Җырлы-биюле уен. «Бар матур бакча».**</u><br>**Балалар түгәрәктә җырлап йөриләр, сүзләргә туры килгән хәрәкәтләрне күрсәтәләр.** | Битлекләр: кишер, алма, руль.<br>Аудиоязма 6. |

© НЕТЕР РН.

| Тема | Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| | | **Чакырылган персонаж уртага чыгып бии, балалар кул чабалар. Соңыннан ике бала «капка» ясап басалар, калганнары бер-бер артлы «капкадан» чыгып китәләр.**<br>1) Бар матур бакча,<br>Анда кишер үсә. *(Түгәрәктә йөриләр.)*<br>Менә шундый кишер зур,<br>Менә шундый кечкенә. *(Хәрәкәт белән күрсәтәләр.)*<br>*Кушымта:*<br>Кишер, кишер, кил әле,<br>Биеп, биеп кит әле. *(Бер бала – «кишер» – уртага чыга, бии.)*<br>Әллә-лә, әллә-лә,<br>Биеп, биеп кит әле. *(Балалар кул чабалар.)*<br>2) Бар матур бакча,<br>Анда алма үсә. *(Түгәрәктә йөриләр.)*<br>Менә шундый алма зур *(түгәрәктә йөриләр),*<br>Менә шундый кечкенә. (*Күрсәтәләр.)*<br>*Кушымта:*<br>Алма, алма, кил әле,<br>Биеп, биеп кит әле. *(Бер бала – «алма» – уртага чыга, бии.)*<br>Әллә-лә, әллә-лә,<br>Биеп, биеп кит әле. *(Балалар кул чабалар.)*<br>3) Шофер, шофер, кил әле,<br>Биеп, биеп кит әле. *(Бер бала – «шофер» – уртага чыга, бии.)*<br>Әллә-лә, әллә-лә,<br>Биеп, биеп кит әле. *(Балаларны «капкадан» алып чыгып китә.)* | |

© НЕТЕР Р.Н.

| Тема | Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| 10. «Серле янчык» | суган, бәрәңге,<br>*1–10 га кадәр санау.* | **<u>1. Дидактик уен «Серле янчык».</u>**<br>**Мияу белән Акбай төрле зурлыктагы кишер, суган, бәрәңге муляжлары тутырылган янчык күтәреп керәләр.**<br>*<u>Аудио (7 нче кисәк)</u>*<br>**Мияу, Акбай:** Исәнмесез, балалар.<br>**Балалар:** Исәнме, Акбай. Исәнме, Мияу. Хәлләрегез ничек?<br>**Мияу, Акбай:** Әйбәт.<br>**Тәрбияче:** Мияу и Акбай принесли волшебный мешочек. Давайте узнаем, что у них в мешочке.<br>**Акбай янчыктан кишер алып күрсәтә:**<br>– Бу нәрсә?<br>**Тәрбияче белән балалар:** Кишер.<br>**Акбай:** Кишер нинди?<br>**Тәрбияче белән балалар:** Кишер зур (кечкенә).<br>**Акбай янчыктан суган алып күрсәтә:**<br>– Бу нәрсә?<br>**Мияу:** Суган.<br>**Мияу янчыктан бәрәңге алып күрсәтә:**<br>– Бу нәрсә?<br>**Акбай:** Бәрәңге.<br>***Суган, бәрәңге*** **сүзләре яңа сүз бирү алымнарын кулланып өйрәтелә.**<br>**2. Акбай, Мияу балалар белән диалог оештыралар.**<br>**а) Акбай:** Бу нәрсә?<br>**Оля:** Суган.<br>**Акбай:** Суган нинди?<br>**Оля:** Кечкенә.<br>**б) Мияу:** Бу нәрсә?<br>**Коля:** Бәрәңге. | Серле янчык.<br>Һәр балага җитәрлек төрле зурлыктагы муляжлар: кишер, суган, бәрәңге.<br>Әби (курчак).<br>Кәрзин.<br>Аудиоязма 7. |

© НЕТЕР...

| Тема | Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| | | **Мияу:** Бәрәңге нинди?<br>**Коля:** Зур.<br>**3. Дидактик уен «Сана».**<br>**Янчыктан муляжларны алып бетергәч, тәрбияче сорый:** Ничә суган (бәрәңге)? Сана.<br>**Балалар:** Ике суган (бәрәңге). 1–10 га кадәр санау.<br>**4. Уен ситуациясе «Әби кунакка килгән».**<br>**Әби ишек шакый. Әбинең кәрзинендә суган, алма, кишер, бәрәңге. Тәрбияче курчак әби ролендә. Кәрзиндәге яшелчә исемнәрен дөрес әйткән балага яшелчәләр таратыла.**<br>**Балалар:** Кем анда?<br>**Әби керә:** Мин, әби.<br>**Балалар:** Әби, кил монда. Исәнме, әби.<br>**Әби:** Исәнмесез, балалар. Кәрзиндә нәрсә бар?<br>**Балалар:** Кишер?<br>**Әби:** Юк.<br>**Балалар:** Алма?<br>**Әби:** Юк.<br>**Балалар:** Суган?<br>**Әби:** Юк.<br>**Балалар:** Бәрәңге.<br>**Әби:** Әйе, бәрәңге (суган, алма, кишер). | |
| 11. «Серле кәрзин» | кыяр | **1. Уен ситуациясе «Бабай кунакка килгән».**<br>**Бабай ишек шакый. Бабайның кәрзинендә яшелчә муляжлары. Тәрбияче бабай ролендә.**<br>**Тәрбияче:** Кто-то стучится. Давайте узнаем, кто там?<br>**Балалар:** Кем анда?<br>**Бабай керә:** Мин – бабай. | Бабай (курчак).<br>Кәрзин.<br>Һәр балага җитәрлек муляжлар: кыяр, кишер, суган, бәрәңге. |

© НЕТЕР.Н.

| Тема | Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| | | **Балалар:** Бабай, кил монда, утыр. Исәнме, бабай.<br>**Бабай:** Исәнмесез, балалар.<br>**Бабай:** Кәрзиндә нәрсә бар?<br>**Балалар:** Кишер?<br>**Бабай:** Юк.<br>**Балалар:** Бәрәңге?<br>**Бабай:** Юк.<br>**Балалар:** Суган?<br>**Бабай:** Юк. Бу – кыяр.<br>***Кыяр* сүзе яңа сүз бирү алымнарын кулланып өйрәтелә.**<br>**2. Дидактик уен «Сана, ничә кыяр?»**<br>**3. Уен ситуациясе «Сорап ал».**<br>**Балаларга суган, кишер, кыяр, бәрәңге муляжлары таратыла. Балалар парлашып уйныйлар.**<br>**Коля:** Оля, кыяр (суган, кишер, бәрәңге) бир.<br>**Оля:** Мә кыяр (суган, кишер, бәрәңге).<br>**Коля:** Рәхмәт.<br>**Уен шулай дәвам итә.**<br>**4. Сүзле уен «Нинди?»**<br>**Яшелчә турында сүзтезмә әйтеп, муляжларны кәрзингә салу:** Кыяр (бәрәңге, суган, кишер) зур (кечкенә, тәмле).<br>**5. Дәфтәрдә эш. 3 нче бирем «Огород».** | Эш дәфтәре. |
| 12. «Бар матур бакча» | | **1. Аудиоязманы тыңлап, кушылып җырлау.**<br>*Аудио (8 нче кисәк)*<br>**Җырлы-биюле уен. «Бар матур бакча».**<br>**Балалар түгәрәктә җырлап йөриләр, сүзләргә туры килгән хәрәкәтләрне күрсәтәләр. Чакырыл-** | Битлекләр: кишер, суган, кыяр, бәрәңге.<br>Руль.<br>Аудиоязма 8. |

| Тема | **Актив сүзләр** *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| | | **ган персонаж уртага чыгып бии, балалар кул чабалар. Соңыннан ике бала «капка» ясап басалар, калганнары бер-бер артлы «капкадан» чыгып китәләр.**<br>1) Бар матур бакча,<br>Анда бәрәңге үсә. *(Түгәрәктә йөриләр.)*<br>Бәрәңге шундый зур,<br>Бәрәңге кечкенә. *(Хәрәкәт белән күрсәтәләр.)*<br>*Кушымта:*<br>Бәрәңге, кил әле,<br>Биеп, биеп кит әле. *(Бер бала «бәрәңге» уртага чыга, бии.)*<br>Әллә-лә, әллә-лә,<br>Биеп, биеп кит әле. *(Балалар кул чабалар.)*<br>2) Бар матур бакча,<br>Анда суган үсә.<br>Менә шундый суган зур *(түгәрәктә йөриләр),*<br>Менә шундый кечкенә *(күрсәтәләр).*<br>*Кушымта:*<br>Суган, суган, кил әле,<br>Биеп, биеп кит әле. *(Бер бала «суган» уртага чыга, бии).*<br>Әллә-лә, әллә-лә,<br>Биеп, биеп кит әле. *(Балалар кул чабалар.)*<br>3) Бар матур бакча,<br>Анда кыяр үсә.<br>Менә шундый кыяр зур *(түгәрәктә йөриләр),*<br>Менә шундый кечкенә (*күрсәтәләр).*<br>*Кушымта:*<br>Кыяр, кыяр, кил әле,<br>Биеп, биеп кит әле. | |

© НЕТЕР Р.Н.

| Тема | Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| | | *(Бер бала «кыяр» уртага чыга, бии.)*<br>Әллә-лә, әллә-лә,<br>Биеп, биеп кит әле. *(Балалар кул чабалар.)*<br>4) Шофер, шофер, кил әле,<br>Биеп, биеп кит әле.<br>Әллә-лә, әллә-лә,<br>Биеп, биеп кит әле. *(Бер бала «шофер» уртага чыга, бии, балаларны «капкадан» алып чыгып китә.)* | |
| 13. «Без хезмәт яратабыз» | кәбестә, нинди? | **1. Дидактик уен «Серле янчык».**<br>**Мияу белән Акбай төрле зурлыктагы кишер, суган, бәрәңге, кәбестә муляжлары тутырылган янчык күтәреп керәләр.**<br>*Аудио (9 нчы кисәк)*<br>**Мияу, Акбай:** Исәнмесез, балалар.<br>**Балалар:** Исәнме, Акбай. Исәнме, Мияу. Хәлләрегез ничек?<br>**Мияу, Акбай:** Әйбәт.<br>**Тәрбияче:** Мияу и Акбай принесли волшебный мешочек. Узнайте на ощупь, что у них в мешочке.<br>**Акбай:** Бу кишер?<br>**Мияу:** Юк.<br>**Акбай:** Бу суган?<br>**Мияу:** Юк.<br>**Акбай:** Бу кәбестә?<br>**Мияу:** Әйе, кәбестә.<br>***Кәбестә* сүзе яңа сүз бирү алымнарын кулланып өйрәтелә.**<br>**Балалар шул үрнәктә янчыктагы яшелчәләрне капшап карыйлар, исемнәрен әйтәләр.**<br>**2. Сүзле уен «Ватык телефон».**<br>**«Кәбестә», «зур кәбестә», «кечкенә кәбестә», «тәмле кәбестә» сүзтезмәләрен кулланып.** | Бер зур, төрле төстәге дүрт кечкенә кәрзин.<br>Һәр балага җитәрлек муляжлар: кишер, кыяр, суган, кәбестә, бәрәңге.<br>Күрсәтмә рәсемнәр: бер кәбестә – ун кәбестә.<br>Ясалган рәсемнәр.<br>Аудиоязма 9–11. |



© НЕТЕРР.Н.

| Тема | Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| | | <u>**3. Сүзле уен «Нәрсә, нинди, ничә?»**</u><br>**Акбай кәрзиннән бер (ике–ун) кәбестә алып күрсәтә:** Бу нәрсә?<br>**Бала:** Кәбестә.<br>**Акбай:** Кәбестә нинди?<br>**Бала:** Кәбестә зур (кечкенә, тәмле).<br>**Акбай:** Ничә кәбестә?<br>**Бала:** Бер кәбестә (1 дән 10 га кадәр).<br><u>**4. Уен ситуациясе «Мин әйтәм, син күрсәт».**</u><br>***Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була.***<br><u>*Аудио (10 нчы кисәк)*</u><br>**Тәрбияче:** Я назову количество овощей, а вы найдите рисунок, покажите, назовите.<br>**Мияу:** Бер кәбестә.<br>**Оля күрсәтә, әйтә:** Бер кәбестә.<br>**Мияу:** Өч кәбестә.<br>**Коля күрсәтә һәм әйтә:** Өч кәбестә.<br>**Башка балалар белән эшчәнлек кабатлана.**<br><u>**5. Сюжетлы-рольле уен «Яшелчәләр кибете».**</u><br>**Сатучы ролендә – Акбай, сатып алучы ролендә – Мияу.**<br><u>*Аудио (11 нче кисәк).*</u><br>а) **Мияу:** Исәнме, Акбай.<br>**Акбай:** Исәнме, Мияу.<br>**Мияу:** Хәлләр ничек?<br>**Акбай:** Әйбәт.<br>**Мияу:** Акбай, кәбестә бир.<br>**Акбай:** Нинди кәбестә?<br>**Мияу:** Зур кәбестә.<br>**Акбай:** Ничә кәбестә?<br>**Мияу:** Бер кәбестә. | |

© НЕТЕР Р.Н.

| Тема | **Актив сүзләр** *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| | | **Акбай:** Мә бер кәбестә.<br>**Мияу:** Рәхмәт, Мияу. Сау бул.<br>**Акбай:** Сау бул, Акбай.<br>**Эшчәнлек балалар арасында дәвам итеде.**<br>б) **Коля:** Исәнме, Оля.<br>**Оля:** Исәнме, Коля.<br>**Коля:** Хәлләр ничек?<br>**Оля:** Әйбәт.<br>**Коля:** Оля, ике кәбестә бир.<br>**Оля:** Мә ике кәбестә.<br>**Коля:** Рәхмәт, Оля. Сау бул.<br>**Оля:** Сау бул, Коля. | |
| 14. «Яшелчәләр кибете» | | **<u>1. Сюжетлы-рольле уен «Яшелчәләр кибете».</u>**<br>**Коля – бәрәңге, Оля – суган, Акбай – кыяр, Мияу кәбестә саталар. Сатып алучылар ролендә балалар.**<br>а) **Маша:** Исәнме, Коля.<br>**Коля:** Исәнме, Маша.<br>**Маша:** Хәлләр ничек?<br>**Коля:** Әйбәт.<br>**Маша:** Коля, 2 бәрәңге бир.<br>**Коля:** Мә, 2 бәрәңге.<br>**Маша:** Рәхмәт, Коля. Сау бул.<br>**Коля:** Сау бул, Маша.<br>б) **Саша:** Исәнме, Оля.<br>**Оля:** Исәнме, Саша.<br>**Саша:** Хәлләр ничек?<br>**Оля:** Әйбәт.<br>**Саша:** Оля, 3 суган бир.<br>**Оля:** Мә, 3 суган.<br>**Саша:** Рәхмәт, Оля. Сау бул.<br>**Оля:** Сау бул, Саша.<br>**<u>2. Дәфтәрдә эш. 4 нче бирем «Сад».</u>**<br>***Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була.*** | Һәр балага җитәрлек муляжлар: кыяр, суган, кәбестә, бәрәңге.<br>Эш дәфтәре. |



© НЕТЕР Р.Н.

| Тема | Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| 15. «Уйный-уйный эшлибез» | | **1. Мультфильм «Уйный-уйный эшлибез».**<br>**2.Аудиоязманы тыңлау, кушылып җырлау.**<br>*Аудио (12 нче кисәк)*<br>**Җырлы-биюле уен. «Бар безнең бакчабыз».**<br>**Балалар түгәрәктә җырлап йөриләр, сүзгә туры килгән хәрәкәтләрне күрсәтәләр. Чакырылган персонаж уртага чыгып бии, балалар кул чабалар. Соңыннан ике бала «капка» ясап басалар, калганнары бер-бер артлы «капкадан» чыгып китәләр.**<br>1) Бар матур бакча,<br>Анда кишер үсә.<br>Менә шундый кишер зур,<br>Менә шундый кечкенә. *(Түгәрәктә йөриләр, хәрәкәт белән күрсәтәләр.)*<br>*Кушымта:*<br>Кишер, кишер, кил әле,<br>Биеп, биеп кит әле. *(Бер бала – «кишер» – уртага чыга, бии.)*<br>Әллә-лә, әллә-лә,<br>Биеп, биеп кит әле. *(Балалар кул чабалар.)*<br>2) Бар матур бакча,<br>Анда суган үсә.<br>Менә шундый суган зур *(түгәрәктә йөриләр),*<br>Менә шундый кечкенә *(күрсәтәләр).*<br>*Кушымта:*<br>Суган, суган, кил әле,<br>Биеп, биеп кит әле. *(Бер бала – «суган» – уртага чыга, бии.)*<br>Әллә-лә, әллә-лә,<br>Биеп, биеп кит әле. *(Балалар кул чабалар.)* | Битлекләр: кишер, суган, кыяр, бәрәңге. Руль. Аудиоязма 12. |

| Тема | Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| | | 3) Бар матур бакча,<br>Анда кыяр үсә. *(Түгәрәктә йөриләр.)*<br>Менә шундый кыяр зур *(түгәрәктә йөриләр),*<br>Менә шундый кечкенә *(күрсәтәләр).*<br>*Кушымта:*<br>Кыяр, кыяр, кил әле,<br>Биеп, биеп кит әле. *(Бер бала – «кыяр» – уртага чыга, бии.)*<br>Әллә-лә, әллә-лә,<br>Биеп, биеп кит әле. *(Балалар кул чабалар.)*<br>4) Шофер, шофер, кил әле,<br>Биеп, биеп кит әле. *(Бер бала – «шофер» – уртага чыга, бии.)*<br>Әллә-лә, әллә-лә,<br>Биеп, биеп кит әле. *(Балаларны «капкадан» алып чыгып китә.)* | |
| 16. «Төсләр дөньясы» | кызыл, сары<br>*Сөйләм үрнәге: сикер, туп.* | **<u>1. Уен ситуациясе «Акбай белән Мияуның төсле туплары».</u>**<br>**Акбайда – кызыл, Мияуда сары туп.**<br>*<u>Аудио (13 нче кисәк)</u>*<br>**Акбай, Мияу:** Исәнмесез, балалар.<br>**Балалар:** Исәнме, Акбай. Исәнме, Мияу.<br>**Акбай, Мияу:** Хәлләрегез ничек?<br>**Балалар:** Әйбәт.<br>**Акбай белән Мияу арасында диалог.**<br>*<u>Аудио (13 нче (а) кисәк)</u>*<br>**Акбай:** Бу нәрсә? (Кызыл туп күрсәтә.)<br>**Мияу:** Туп.<br>**Акбай:** Туп нинди?<br>**Мияу:** Туп кызыл.<br>*<u>Аудио (13 нче (б) кисәк)</u>*<br>**Мияу:** Бу нәрсә? (Сары туп күрсәтә.) | Уенчык эт Акбай, песи Мияу.<br>Таратма һәм күрсәтмә рәсемнәр: кызыл туп, сары туп, кызыл алма, сары алма.<br>Сары, кызыл туплар.<br>Аудиоязма 13 (а, б) –19. |



© НЕТЕР Р.Н.

| Тема | Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| | | **Акбай:** Туп.<br>**Мияу:** Туп нинди?<br>**Акбай:** Туп сары.<br>**<u>2. Аудиоязманы тыңлау.</u>**<br>*<u>Аудио (14 нче кисәк)</u>*<br>*<u>«Слушай!» – «Тыңла!»</u>*<br>**Тәрбияче сары туп рәсемен күрсәтә.**<br>– Бу нәрсә?<br>– Туп.<br>– Туп нинди?<br>– Сары.<br>**<u>3. Аудиоязманы тыңлау, кабатлау.</u>**<br>*<u>Аудио (15 нче кисәк)</u>*<br>*<u>«Слушай, повтори!» – «Тыңла, кабатла!»</u>*<br>**Тәрбияче сары туп рәсемен күрсәтә, балалар аудиодан ишеткән сүзне кабатлыйлар.**<br>– Бу туп.<br>– Туп сары.<br>**<u>4. Аудиоязманы тыңлау.</u>**<br>*<u>Аудио (16 нчы кисәк)</u>*<br>*<u>«Слушай!» – «Тыңла!»</u>*<br>**Тәрбияче кызыл туп рәсеме күрсәтә.**<br>– Бу нәрсә?<br>– Туп.<br>– Туп нинди?<br>– Кызыл.<br>**<u>5. Аудиоязманы тыңлау, кабатлау.</u>**<br>*<u>Аудио (17 нче кисәк)</u>*<br>*<u>«Слушай, повтори!» – «Тыңла, кабатла!»</u>*<br>**Тәрбияче кызыл туп рәсемен күрсәтә, балалар аудиодан ишеткән сүзне кабатлыйлар.**<br>– Бу туп.<br>– Туп кызыл. | |

© НЕТЕР.Н.

| Тема | Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| | | **<u>6. Аудиоязманы тыңлау, кушылып җырлау.</u>**<br>*<u>Аудио (18 нче кисәк)</u>*<br>Туп, туп, кызыл туп.<br>Сикер, сикер, кызыл туп.<br>Туп, туп, сары туп.<br>Сикер, сикер, сары туп.<br>**<u>7. Дидактик уен «Нинди төс юк?»</u>**<br>***Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була.***<br>**Кызыл алма, сары алма, кызыл туп, сары туп рәсемнәре күрсәтелә, төсләре әйтелә. Тәрбияче бер рәсемне яшерә, сорый:** Нинди алма юк?<br>**Балалар:** Кызыл (сары) алма юк.<br>**Уен башка рәсемнәр белән шул үрнәктә дәвам итә.**<br>**<u>8. Үстерешле уен «Мин нәрсә уйладым?»</u>**<br>**Кызыл, сары алма рәсемнәре күрсәтелә, балалар сүзтезмәләрне кабатлыйлар. Тәрбияче Акбай ролендә. Акбай сүзтезмәне уйлый. Балалар нинди сүзтезмә уйлаганын белеп әйтәләр.**<br>**а) Балалар:** Кызыл алма?<br>**Акбай:** Юк.<br>**Балалар:** Сары алма?<br>**Акбай:** Әйе, сары алма.<br>**б) Бала рәсемдәге сүзтезмәне уйлый. Балалар нинди сүзтезмә уйлаганын белеп әйтәләр.**<br>**Балалар:** Кызыл туп?<br>**Бала:** Юк.<br>**Балалар:** Сары туп?<br>**Бала:** Әйе, сары туп. | |

© НЕГЕР.Р.Н.

| Тема | Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| | | **9. Хәрәкәтле уен «Туп».**<br>**Балаларга кызыл, сары туплар таратыла. Уенның эчтәлегенә туры китереп хәрәкәтләр ясала.**<br>*Аудио (19 нчы кисәк)*<br>1) Туп, туп, кызыл туп,<br>Сикер, сикер, кызыл туп.<br>Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, тугыз, ун,<br>Сикер, сикер, кызыл туп.<br>2) Туп, туп, сары туп,<br>Сикер, сикер, сары туп.<br>Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, тугыз, ун,<br>Сикер, сикер, сары туп. | |
| 17. «Төсләр дөньясы» | яшел | **1. Уен ситуациясе «Яшел туп».**<br>**Тәрбияче яшел туп күрсәтә, сорый:** Бу нәрсә?<br>**Бала:** Туп.<br>**Тәрбияче:** Туп нинди?<br>**Бала:** Туп матур (чиста, зур, кечкенә).<br>**Тәрбияче:** Скажите, какого цвета мяч?<br>Да, зеленый – яшел.<br>***Яшел* сүзе яңа сүз бирү алымнарын кулланып өйрәтелә.**<br>**2. Дидактик уен «Нинди туп юк?»**<br>**Балалар алдында кызыл, сары, яшел туплар.**<br>**Тәрбияче:** Туп нинди?<br>**Бала:** Туп яшел (кызыл, сары).<br>**Тәрбияче бер тупны яшерә, сорый:** Нинди туп юк?<br>**Бала:** Яшел туп юк (кызыл, сары).<br>**3. Дәфтәрдә эш. 5 нче бирем «Слушай, найди, отметь».**<br>***Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була.*** | Күрсәтмә рәсемнәр: яшел, кызыл, сары алмалар, туплар.<br>Эш дәфтәре, карандашлар.<br>Аудиоязма 20. |



© НЕТЕР Р.Н.

| Тема | Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| | | **<u>4. Аудиоязманы тыңлау, кушылып җырлау.</u>**<br>*<u>Аудио (20 нче кисәк)</u>*<br>**Балаларга сары, кызыл, яшел туплар таратыла. Алар уенның эчтәлегенә туры китереп хәрәкәтләр ясыйлар.**<br>1) Туп, туп, кызыл туп,<br>Сикер, сикер, кызыл туп.<br>Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, тугыз, ун,<br>Сикер, сикер, кызыл туп.<br>2) Туп, туп, сары туп,<br>Сикер, сикер, сары туп.<br>Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, тугыз, ун,<br>Сикер, сикер, сары туп.<br>3) Туп, туп, яшел туп,<br>Сикер, сикер, яшел туп.<br>Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, тугыз, ун,<br>Сикер, сикер, яшел туп. | |
| 18. «Юл мажаралары». | | **<u>Мультфильм «Юл мажаралары».</u>** | |
| 19. «Яшелчә салаты» | кирәк, нәрсә кирәк?<br>*Сөйләм үрнәге: нинди?* | **<u>1. Уен ситуациясе «Салат өчен нәрсә кирәк?»</u>**<br>*<u>Аудио (21 нче кисәк)</u>*<br>Заяц хотел приготовить овощной салат. Давайте поможем выбрать овощи. Что нужно для салата? Нәрсә кирәк?<br>**Тәрбияче, яшелчәләрне күрсәтеп, Акбайдан сорый:**<br>Кишер кирәк?<br>**Акбай:** Кирәк.<br>**Тәрбияче:** Суган кирәк?<br>**Акбай:** Кирәк.<br>**Тәрбияче:** Помидор кирәк?<br>**Акбай:** Кирәк. | Муляжлар: кишер, суган, кәбестә, бәрәңге, помидор, кыяр.<br>Аудиоязма 21, 21 (а). |

© НЕ ПЕР Р.Н.

| Тема | **Актив сүзләр** *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| | | **Тәрбияче:** Кыяр кирәк?<br>**Акбай:** Кирәк.<br>**Тәрбияче:** Кәбестә кирәк?<br>**Акбай:** Кирәк.<br>**Тәрбияче:** Бәрәңге кирәк?<br>**Акбай:** Кирәк.<br>*Аудио (21 нче (а) кисәк)*<br>**Балалар тәрбияче ярдәмендә кабатлыйлар:**<br>– Кишер кирәк.<br>– Суган кирәк.<br>– Помидор кирәк.<br>– Кыяр кирәк.<br>– Кәбестә кирәк.<br>– Бәрәңге кирәк.<br>***Кирәк* сүзе яңа сүз бирү алымнарын кулланып өйрәтелә.**<br>**2. Үстерешле уен «Нәрсә, нинди, ничә?»**<br>**Диалоглар балалар белән балалар арасында үткәрелә.**<br>а) **Оля:** Коля, нәрсә кирәк?<br>**Коля:** Бәрәңге кирәк.<br>**Оля:** Ничә бәрәңге?<br>**Коля:** Сигез бәрәңге.<br>**Оля:** Мә, сигез бәрәңге.<br>**Коля:** Рәхмәт.<br>б) **Коля:** Оля, нәрсә кирәк?<br>**Оля:** Помидор кирәк.<br>**Коля:** Нинди помидор?<br>**Оля:** Кызыл помидор.<br>**Коля:** Мә, кызыл помидор.<br>**Оля:** Рәхмәт.<br>в) **Коля:** Оля, нәрсә кирәк?<br>**Оля:** Кәбестә кирәк.<br>**Коля:** Ничә кәбестә?<br>**Оля:** Дүрт кәбестә.<br>**Коля:** Мә, дүрт кәбестә.<br>**Оля:** Рәхмәт. | |

© НЭТЕР Р.Н.

| Тема | **Актив сүзләр** *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| 20. «Яшелчә ю» | юа, су | **<u>1. Уен ситуациясе «Яшелчә ю».</u>**<br>**Тәрбияче:** Кыяр (кәбестә, суган, кишер, помидор, бәрәңге) нинди?<br>**Балалар:** Кыяр (кәбестә, суган, кишер, помидор, бәрәңге) пычрак.<br>**Тәрбияче балаларга яшелчәләрне юарга тәкъдим итә:** Мә су, кыяр (кәбестә, суган, кишер, помидор, бәрәңге) ю.<br>**Балалар бер-берсенә яшелчәләр юарга тәкъдим итәләр.**<br>**Оля:** Коля, кил монда. Мә су, кыяр ю.<br>**<u>2. Ситуатив күнегү «Яшелчә юабыз».</u>**<br>**Балалар яшелчәләрне юалар.**<br>**Тәрбияче:** Саша кыяр юа.<br>**Бергә:** Саша кыяр юа.<br>**Тәрбияче:** Маша моет помидор. Оля, как ты скажешь по-татарски, что Маша моет помидор?<br>**Оля:** Маша помидор юа.<br>**Башка балалар белән дә ситуатив күнегү кабалана.**<br>**<u>3. Уен ситуациясе «Куянга яшелчә бир».</u>**<br>***Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була.***<br>**Бала:** Куян, мә кыяр (суган, кишер, кәбестә, помидор, бәрәңге).<br>**Куян:** Рәхмәт.<br>**<u>4. Дәфтәрдә эш. 6 нчы бирем «Кто что делает?»</u>**<br>***Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була.*** | Муляжлар: кишер, суган, кәбестә, бәрәңге, помидор, кыяр.<br>Эш дәфтәре. |
| 21. «Кем эшләми, шул ашамый» | | **<u>Мультфильм «Кем эшләми, шул ашамый».</u>** | |



© НЕТЕР Р.Н.

| Тема | Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| 22. «Яшелчәләр кибете» | | **<u>1. Сюжетлы-рольле уен «Яшелчәләр кибете».</u>**<br>**Диалоглар балалар белән балалар арасында үткәрелә.**<br>а) – Коля, нәрсә кирәк?<br>– Бәрәңге кирәк.<br>– Мә, бәрәңге.<br>– Рәхмәт.<br>б) – Оля, нәрсә кирәк?<br>– Алма кирәк.<br>– Нинди алма?<br>– Яшел алма.<br>– Мә, яшел алма.<br>– Рәхмәт.<br>в) – Лена, нәрсә кирәк?<br>– Кәбестә кирәк.<br>– Ничә кәбестә?<br>– Дүрт кәбестә.<br>– Мә, дүрт кәбестә.<br>– Рәхмәт. | |
| 23. «Уйныйбыз да, җырлыйбыз да» | *Сөйләм үрнәге: нәрсә бар?* | **<u>1. Җырлы-биюле уен «Кемгә нәрсә кирәк?»</u>**<br>*<u>Аудио (22 нче кисәк)</u>*<br>**Балалар, төрле яшелчә битлекләре киеп, түгәрәктә җырлап әйләнәләр. Бер баланың битлеге юк, ул баладан сорыйлар:**<br>Миңа кыяр кирәк,<br>Сиңа кыяр кирәк.<br>Әйе шул, әйе шул,<br>Сиңа нәрсә кирәк?<br>**Битлексез бала:** Кәбестә (бәрәңге, кыяр, кишер, суган, помидор) кирәк.<br>**Кәбестә битлеге кигән бала белән битлексез бала куышалар, түгәрәктә балалар җырлап торалар:**<br>Әйе шул, әйе шул,<br>Сиңа кәбестә кирәк. | Төрле зурлыкта һәр балага җитәрлек муляжлар: суган, кишер, кыяр, кәбестә, бәрәңге, алма, (кызыл, сары, яшел). Аудиоязма 22, 22 (а) (фонограмма), 23. |



© НЕТЕР Р.Н.

| Тема | Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| | | **Очрашкач, кәбестә битлеге кигән бала үзенең битлеген битлексез балага бирә. Уен шулай дәвам итә.**<br>**<u>2. Җырлы-биюле уен «Кәрзиндә нәрсә бар?»</u>**<br>**Тәрбияче белән балалар арасында диалог рәвешендә җырлана.**<br><u>*Аудио (23 нче кисәк)*</u><br>1.– Оля, Оля, әйт әле,<br>Кәрзиндә нәрсә бар?<br>– Кәрзиндә кызыл, сары,<br>Яшел матур алма бар.<br>2.– Саша, Саша, әйт әле,<br>Кәрзиндә нәрсә бар?<br>– Кәрзиндә кыяр, суган,<br>Кәбестә бар, кишер бар. | |
| 24. «Уңыш бәйрәме» | | **<u>1. Дидактик уен «Серле кәрзин».</u>**<br>**Уңыш бабай керә. Кәрзинендә яшелчәләр. Кәрзиндәге бер яшелчәне балаларга күрсәтмичә сорый**: Кәрзиндә нәрсә бар?<br>**Балалар:** Алма.<br>**Уңыш бабай:** Юк, кәбестә.<br>**Уен суган, кишер, кыяр, алмаларны алып бетергәнче дәвам итә.**<br>**<u>2. Аудиоязманы тыңлау, кушылып җырлау.</u>**<br><u>*Аудио (24 нче кисәк)*</u><br>**Уңыш бабай белән балалар арасында диалог рәвешендә җырлана.**<br>1. – Бабай, бабай, әйт әле,<br>Кәрзиндә нәрсә бар?<br>– Кәрзиндә кызыл, сары,<br>Яшел, матур алма бар.<br>2. – Бабай, бабай, әйт әле,<br>Кәрзиндә нәрсә бар? | Һәр балага җитәрлек санынча суган, кишер, кыяр, кәбестә, алма муляжлары һәм яшелчә битлекләре. Дүрт кәрзин. Аудиоязма 24, 22 (кабатлана). |



© НЕГЕР Р.Н.

| Тема | Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| | | – Кәрзиндә кыяр, суган,<br>Кәбестә бар, кишер бар.<br>**3. Уен-эстафета «Уңыш җыябыз».**<br>**Бер түгәрәктә яшелчәләр сибелеп ята. Балалар дүрт командага бүленгән. Һәр команда, биремне тыңлап, билгеле бер яшелчәне җыя.**<br>**Тәрбияче:** Каждая команда собирает определенный овощ.<br>**4. Җырлы уен «Кемгә нәрсә кирәк?»**<br>*Аудио (22 нче кисәк)*<br>**Балалар, төрле яшелчә битлекләре киеп, түгәрәктә җырлап әйләнәләр. Бер баланың битлеге юк, ул баладан сорыйлар:**<br>Миңа кыяр кирәк,<br>Сиңа кыяр кирәк.<br>Әйе шул, әйе шул,<br>Ә сиңа нәрсә кирәк?<br>**Битлексез бала:** Кәбестә (бәрәңге, кыяр, кишер, суган, помидор) кирәк.<br>**Кәбестә битлеге кигән бала белән битлексез бала куышалар, түгәрәктә балалар җырлап торалар:**<br>Әйе шул, әйе шул,<br>Сиңа кәбестә кирәк.<br>**Очрашкач, кәбестә битлеге кигән бала үзенең битлеген битлексез балага бирә. Уен шулай дәвам итә.** | |
| 25. «Ашамлыклар» | аш,<br>ботка | **Мы пришли в кафе. Давайте познакомимся с меню, что нам предлагают кушать.**<br>**1. Аудиоязманы тыңлау.**<br>*Аудио (25 нче кисәк)*<br>*«Слушай!» – «Тыңла!»*<br>**Тәрбияче ипи, сөт, чәй, аш, ботка рәсемнәрен күрсәтә.** | Күрсәтмә һәм таратма ашамлык рәсемнәре: ипи, сөт, чәй, аш, ботка. |

© НЕТЕР.Н.

| Тема | Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| | | – Ипи.<br>– Чәй.<br>– Сөт.<br>– Аш.<br>– Ботка.<br>**2. Аудиоязманы тыңлау, кабатлау.**<br>**Тәрбияче рәсемнәрне күрсәтә, балалар аудиодан ишеткән сүзне кабатлыйлар.**<br>*Аудио (26 нчы кисәк)*<br>*«Слушай, повтори!» – «Тыңла, кабатла!»*<br>– Ипи.<br>– Чәй.<br>– Сөт.<br>– Аш.<br>– Ботка.<br>**3. Дидактик уен «Дөрес күрсәт».**<br>*Аудио (27 нче кисәк)*<br>*«Слушай, покажи, повтори!» – «Тыңла, күрсәт, кабатла!»*<br>**Балалар аудиоязмадан сүзне тыңлый, рәсеме туры килгән бала таратма рәсемнәрне күрсәтә, *тәмле* сүзен кушып әйтә.**<br>– Ипи – тәмле ипи.<br>– Чәй – тәмле чәй.<br>– Сөт – тәмле сөт.<br>– Аш – тәмле аш.<br>– Ботка – тәмле ботка.<br>**4. Сюжетлы-рольле уен «Ашханә».**<br>**Мияу пешекче ролендә. Аңарда таратма рәсемнәр. Балалар рәсемнәрне сорап алалар.**<br>**Бала:** Исәнме, Мияу.<br>**Мияу:** Исәнме, Оля. Нәрсә кирәк?<br>**Оля:** Аш (ботка, чәй, ипи, сөт) кирәк. | Аудиоязма 25–28. |

| Тема | Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| | | **Оля:** Нинди сөт (чәй)?<br>**Коля:** Тәмле сөт (чәй).<br>**Оля:** Мә, сөт (чәй), эч.<br>**Коля:** Рәхмәт. Сөт (чәй) тәмле.<br>**Диалог шул үрнәктә *аша* сүзе кулланып кабатлана.**<br>**<u>6. Аудиоязмадан җыр тыңлау, кушылып җырлау.</u>**<br>*<u>Аудио (28 нче кисәк)</u>*<br>Без ашыйбыз тәмле аш,<br>Тәмле аш, тәмле аш.<br>Без ашыйбыз тәмле ботка,<br>Тәмле ботка, тәмле ботка. | |
| 26. «Ашханә» | | **<u>1. Сюжетлы-рольле уен «Ашханә».</u>**<br>**Мияу пешекче ролендә. Аңарда таратма рәсемнәр. Балалар рәсемнәрне сорап алалар:**<br>**Бала:** Исәнме, Мияу.<br>**Мияу:** Исәнме, Оля. Нәрсә кирәк?<br>**Оля:** Аш (ботка, чәй, ипи, сөт) кирәк.<br>**Мияу:** Нинди аш (ботка, чәй, ипи, сөт)?<br>**Оля:** Тәмле аш (ботка, чәй, ипи, сөт).<br>**Мияу:** Мә, аш (ботка, чәй, ипи, сөт) аша.<br>**Оля:** Рәхмәт. Аш (ботка, чәй, ипи, сөт) тәмле.<br>**Уен шулай башка балалар белән дәвам итә.**<br>**<u>2. Уен ситуациясе «Иптәшеңне сыйла».</u>**<br>**Оля:** Исәнме, Коля.<br>**Коля:** Исәнме, Оля.<br>**Оля:** Нәрсә кирәк?<br>**Коля:** Сөт (чәй) кирәк.<br>**Оля:** Нинди сөт (чәй)? | Таратма рәсемнәр: ашамлыклар.<br>Эш дәфтәре.<br>Аудиоязма 28. |

© НЕТЕР Р.Н.

| Тема | Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)* | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| | | **Коля:** Тәмле сөт (чәй).<br>**Оля:** Мә сөт (чәй) эч.<br>**Коля:** Рәхмәт. Сөт (чәй) тәмле.<br>**Диалог шул үрнәктә *аша* сүзе кулланып кабатлана.**<br>**<u>3. Аудиоязманы тыңлау.</u>**<br>*<u>Аудио (28 нче кисәк)</u>*<br>Без ашыйбыз тәмле аш,<br>Тәмле аш, тәмле аш.<br>Без ашыйбыз тәмле ботка,<br>Тәмле ботка, тәмле ботка.<br>**<u>4. Дәфтәрдә эш. 7 нче бирем «Угости».</u>**<br>***(Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була).*** | |
| 27. «Аш бүлмәсе» | | **<u>Мультфильм «Аш бүлмәсе».</u>** | |
